ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЕЛАБУГА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 06 2019 № 15

Алабуга шәһәрендә һәм Алабуга муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесен раслау турында

«Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Алабуга шәһәрендә һәм Алабуга муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәтенең кушымтада бирелгән расписаниесен расларга (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Е.Н.Николаевка кушымтада бирелгән расписание үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән 30 көн узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен тикшерүдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче К.В. Мокшин